ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.12.2021 Олы Кайбыч ав. № 488

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында Ireклелекне (волонтерлыкны) үстерү буенча ведомствоара совет төзү турында

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында иреклелек (волонтерлык) хәрәкәтен үстерү һәм аңа ярдәм итү максатларында,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында Иреклелекне (волонтерлыкны) үстерү буенча ведомствоара совет төзергә.

2. Расларга:

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында Иреклелекне (волонтерлыкны) үстерү буенча ведомствоара совет турында нигезләмә (1нче кушымта);

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында Иреклелекне (волонтерлыкны) үстерү буенча ведомствоара советы составы (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф.Петуховага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының 13.12
488 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында Иреклелекне (волонтерлыкны) үстерү буенча ведомствоара совет турында
НИГЕЗЛӘМӘ

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында Иреклелекне (волонтерлыкны) үстерү буенча ведомствоара совет (алга таба - Ведомствоара совет) муниципаль хакимият органнарының килештерелгән гамәлләрен һәм аларның иреклелек (волонтерлык) эшчәнлеге өлкәсендәге иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү максатларында төзелгән орган булып тора.

1.2. Ведомствоара совет үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

2. Ведомствоара советның төп бурычлары һәм функцияләре

2.1. Ведомствоара советның төп бурычлары һәм функцияләре:

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль хакимиятенең иреклелек (волонтерлык) мәсьәләләре буенча иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында иреклелекнең (волонтерлыкның) өстенлекле юнәлешләренә ярдәм итү һәм ирекле (волонтерлык) эшчәнлекне гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр булдыру;

иреклелек (волонтерлык) эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча иреклелек (волонтерлык) эшчәнлегенә методик ярдәм (мәгариф, сәламәтлек саклау, граждан-патриотик тәрбия, мәдәният, халыкка социаль ярдәм күрсәтү һәм социаль хезмәт күрсәтү, физик культура һәм спорт, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, эчке эшләр органнарына ярдәм итү, вакыйгалы, инклюзив, корпоратив иреклелек (волонтерлык), өлкән яшьтәге иреклелек (волонтерлык) өлкәсендә - “көмеш волонтерлык”);

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында иреклелек (волонтерлык) эшчәнлегенә комплексы анализ ясау һәм иреклелеккә (волонтерлыкка) ярдәм итүгә кагылышлы тәҗрибәләрне гомумиләштерү.

3. Ведомствоара советның хокуклары

3.1. Үзенә йөкләнгән вазыйфаларны үтәү өчен ведомствоара совет түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында иреклелек (волонтерлык) үсешенең өстенлекле юнәлешләре буенча тәкъдимнәр кертергә;

үз утырышларында ведомствоара совет эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләрне карарга һәм алар буенча карарлар кабул итәргә.

4. Ведомствоара совет составы һәм эшчәнлеген оештыру

4.1. Ведомствоара совет Совет рәисе, рәис урынбасары һәм Советның башка әгъзалары составында төзелә.

4.2. Ведомствоара совет составы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

4.3. Ведомствоара совет рәисе аның эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, Ведомствоара совет утырышларын уздыра, ведомствоара советның эш планын раслый, Ведомствоара совет әгъзалары арасында аңа йөкләнгән бурычлар һәм функцияләр кысаларында бурычларны бүлә, Ведомствоара совет әгъзаларына тиешле йөкләмәләр бирә, беркетмәләргә һәм Ведомствоара советның башка документларына кул куя.

4.4. Ведомствоара совет рәисе булмаган очракта, аның вәкаләтләрен Ведомствоара совет рәисе йөкләмәсе буенча Ведомствоара совет рәисе урынбасары башкара.

4.5. Ведомствоара совет утырышлары кирәк булган саен, ләкин кимендә кварталга бер тапкыр уздырыла. Ведомствоара совет утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми санының кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала. Ведомствоара совет утырышларына материаллар Ведомствоара совет әгъзаларына Ведомствоара совет секретаре тарафыннан Ведомствоара совет утырышын уздыру датасына кадәр өч көннән дә соңга калмыйча таратылырга тиеш.

4.6. Ведомствоара совет әгъзасы Ведомствоара совет утырышларында шәхсән үзе катнашырга тиеш. Утырышта катнашу мөмкинлеге булмаган очракта, Ведомствоара совет әгъзасы бу хакта, булмауның сәбәпләрен күрсәтеп, Ведомствоара совет рәисенә хәбәр итәргә тиеш.

4.7. Ведомствоара совет утырышларында тикшерелә торган мәсьәләләр Ведомствоара совет карары белән рәсмиләштерелә, ул утырышта катнашучы затларның күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә, утырышлар беркетмәләре белән рәсмиләштерелә, алар Ведомствоара совет рәисе тарафыннан имзалана. Тавышлар саны тигез булганда Ведомствоара совет рәисе яки Ведомствоара совет утырышында рәислек итүче Ведомствоара совет рәисе урынбасары тавышы хәлиткеч булып тора.

4.8. Ведомствоара совет утырышы йомгаклары буенча протоколлар утырышны уздырганнан соң 10 эш көне эчендә рәсмиләштерелә һәм Ведомствоара совет рәисе кул куйганнан соң өч көн эчендә Ведомствоара советның республика башкарма хакимияте органнарына һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына кызыксынган барлык әгъзаларына җибәрелә.

4.9. Ведомствоара советның компетенциясе нигезендә кабул ителә торган карарлары тәкъдим характерында.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының 13. 12. 2021
488 номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында Иреклелекне (волонтерлыкны) үстерү буенча ведомствоара советы
СОСТАВы

**Комиссия рәисе:**

| | |
|---|---|
| Петухова Ф.Ф. | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |

**Комиссия рәисе урынбасары:**

| | |
|---|---|
| Лотфуллина З.Ф. | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт бүлеге башлыгы |

**Комиссия әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Хәмидуллин И.И. | «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы |
| Сафина А.Г. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Әбләзова Р.Р | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы |
| Сөнгатуллина Л.М. | «Татмедиа» филиалы «Кайбыч таңнары», «Кайбицкие зори» газетасы директоры- баш мөхәррире (килешү буенча) |
| Сафиуллина Г.И. | «Кайбыч үзәк район хастаханәсе» ДАССО ның баш табибы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Смелов М.В. | Кайбыч муницпаль районы «Экология, мәдәният, мәгариф» мәктәптән тыш эш үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча) |